*Загидуллин И*. **Противостояние**. Идель. 1992. — № 1-2. (на татарском языке)

Статья посвящена истории национально-освободительного движения крестьян Казанской губернии в 1878-79 г.г.

*Заһидуллин И*. Тарих фәннәре кандидаты.

**Гыйсъян** (Милли азатлык хәрәкәте сәхифәләреннән).
Идель. 1992. — № 1-2.

Бүген, татар халкы милли уяну кичергән чорда, тарихның кайбер гыйбрәтле битләренә кабат күз саласы килә.

Сүз 1878–1879 елгы татар крәстияннәре хәрәкәтенең иң көчле чагылышы, иң югары ноктасы булган Казан өязе крәстияннәре фетнәсе хакында барачак. Бу турыда аз язылмады, ләкин хәзер моңарчы яктыртылган, өйрәнелгән вакыйгаларга яңача бәя бирү, идеология белән бастырылып килгән катламнарны кузгатып, халыкка җиткерү вакыты килде.

Бу вакыйгаларны китереп чыгарган сәбәпләрне тарихчылар ике төрле аңлаталар. Берәүләр (Н.Н.Фирсов, Е.И.Чернышев) беренче планга милли аспектны – татар халкының чукындырудан куркуын куялар, икенчеләр исә (И.Л.Морозов, Ю.И.Смыков) авыр социаль-икътисади хәлне һәм милли изүне күрсәтәләр.

1878–1879 еллардагы чуалышлар йомгагының җебе 1878 елда Казан губернасында кабул ителгән “Авыл җәмгыятьләре үтәргә тиеш йөкләмәләр” инструкциясенә барып тоташа. Бу документның нигезендә крәстияннәр хисабына янгын куркынычсызлыгын ныгыту, авыллардагы тормыш-көнкүрешен “тәртипкә салу” теләге ята: авылларда янгын сарайлары төзү, аларны тиешле эш кораллары, атлы һәм җәяүле кизү торучылар белән тәэмин итү һ.б. каралган була. Инструкцияне гамәлгә ашырырга тотынгач, мәсәлән, Чистай өязе Зирекле волостенең 140 хуҗалыклы бер авылында һәр тәүлеккә янгын куркынычсызлыгы өчен 14 ат һәм 26 кеше таләп ителә башлый[1]. Казан губернасында бу хәл булган 1877 елның көчле ачлык елы икәнен дә онытырга ярамый.

Ләкин шунысы гаҗәп, изү-изелүнең көчәюенә карамастан, 1879–1880 елларда, ягъни тарихчылар Рәсәйдәге икенче революцион ситуация еллары дип атаган чорда, Казан губернасы кебек зур өлкәдә татар булмаган халыкларның чыгышлары бармак белән генә санарлык. Алары да 1878–1879 елларга туры килә. Архив материалларына таянып без чуаш, мордва, урыс крәстияннәренең чыгышларын турыдан-туры татарлар катнашында яки алар йогынтысы –коткы таратуы нәтиҗәсендә булган дип кистереп әйтә алабыз.

Ни өчен бу шулай? Салымнар артуын крәстияннәр, язмыштан узмыш юк, шулай булырга тиеш кебек итеп кабул иткәннәр, күрәсең.

Татарлар күңеленә энә булып кадалган сәбәпләр инструкциянең аерым параграфларына яшеренгән була. Документны төзегән урыс чиновниклары, йомшак кына итеп әйткәндә, Казан губернасы милләтенең өчтән бере татарлар икәнен “онытып”, чиркәүләр төзү һәм аларны карап тоту, поплар тарафыннан дин сабагы укытылырга тиеш булган училищелар чыгымнарын авыл мәхәлләләренә йөкләү кебек маддә-параграф-ларны бар халык өчен уртак дип күрсәтәләр. Татар халкы бу инструкцияне көчләп чукындыру өчен әзерләнгән документ дип карый. Инструкциядә таләп ителгәнчә, авыл капкалары янына багана утыртып, анда урысча авыл исемен, хуҗалыклар санын, күпме халык яшәвен язып куюны, авыл уртасындагы колгага янгын куркынычсызлыгы өчен кечкенә генә чаң урнаштыруларны халык башта шунда чукындыру һәм соңрак чиркәү тезү өчен эшләнә дип аңлый. Инструкция китапларының авыл старосталарына җәй көне, июнь-июль айларында, укылмыйча һәм аңлатылмыйча шыпыртын гына таратылып, октябрь башларында гына игълан ителүе шик-шөбһәне тагын да көчәйтә.

Пашта хөкүмәте, 1870 елгы программасын үтәп, мөселманнарны урыс теле укыту аркылы урыслаштыру сәясәтен үткәрмәкче була. Мәктәп-мәдрәсәләрдә авыл

мәхәлләсе хисабына көчләп урыс класслары ачтырырга омтылалар, каршылык булган авыллардагы татар мәктәпләрен ябалар. Әлеге инструкция XVI йөзнең икенче яртысы–XVIII йөз дәвамындагы мәрхәмәт-сезлекләрне, мәчет-мәдрәсәләрне җимерүләрне, көчләп чукындыруларны искә төшерә.

1865–1866 елларда керәшеннәрнең ислам диненә кайту хәрәкәте булып узганнан соң яңа мөселманнарга карата киң кулланылган репрессия чаралары татарларда нәфрәт һәм сагаю тудыра. 1876 елның гыйнварендә Ят диннәр эше буенча департамент белән идарә итүче түрәнең Казан архиепискоы Антонийга язган хатында түбәндәге юллар бар: “Сезгә мәгълүм ки, православиедан язган татарларга карата күптөрле җәза бирү чаралары кулланабыз, юлдан яздыручыларны (мөселманлыкка күчүне башлап һәм оештырып йөрүчеләрне – И.З.) җинаять җаваплылыгына тарту, аларны Себергә каторгага сөрү, төрмәгә ябып кую, балаларын тартып алу, башка авыррак һәм җиңелрәк газаплы җәзалардан тыш, юлдан язганнарны административ тәртиптә күпләп күчерәбез”.

Миссионерлар, христиан дине әһелләре, җирле администрация эшне ике яклап алып баралар. Православиедан ваз кичкәннәрне кире “тәртә арасына” кертү өчен барысы да эшләнә. Шул ук вакытта мондый “күңелсез” хәлләрне башка булдырмау һәм тамырына балта чабу өчен ислам динен “авызлыклау”, аның йогынтысын киметү максатында дөньяви һәм рухани даирәләргә Казаннан карагруһ эчтәлекле тәкъдимнәр, шикаятьләр килә башлый.

Халык арасында төрле сүзләр таралуга сәбәпче булган, имеш-мимешләр куерткан мөһим һәм гыйбрәтле ике сәбәп хакында да әйтми калу мөмкин түгел.

Җирле урыс хакимияте вәкилләре халык күңелен болгатуга, төрле сүзләр таратуга мул өлеш кертәләр. Ул шомлы көннәрдә теге яки бу күрсәтмә үтәлмәгән очракта, гадәттәгечә, ачы сүгенеп, сезне, “татарны чукындырырга кирәк, башкача денгә кермисез”, дип сөйләүләрне халык турыдан-туры кабул итә. Мәсәлән, Чистай өязе исправнигы Мөслим авылында үзенә каршы сүз әйткәннәргә: “Мин сезне чукындырам”,– дип кычкыра. Спасе өязенең Мораса олысы старшинасы белән писаре Үргэгар авылы халкына: “Сезгә болай йөрергә күп калмады инде... Тиздән, 1879 елдан динегезне алыштырабыз, бу хакта инструкция язылган”,– дип белдерәләр[2]. Чуел өязе Акъегет олысының старшина ярдәмчесе Бакырчы авылында җыелган халыкка мәчет янындагы коймага төртеп күрсәтеп “бу урында православие дине гыйбадәтханәсе корылачак, баганага чаң эленәчәк, старосталарга бу турыда китаплар таратылды инде”,– дип игълан итә.

Җирле хакимият вәкилләренең кыланышларыннан куркуга калган авыл мәхәлләләре, үзләренең дип тоту хокукларын яклар дип ышанган Диния Нәзарәтенә хатлар яза башлыйлар. Мөселман динендә калу өчен, чукынмас өчен җанын фида кылырга әзер торган татар халкының ни күрәчәген, авылларда нинди чуалышлар килеп чыгарга мөмкин икәнен яхшы аңлаган мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев Казан губернаторы Н.Я.Скарятинга язган хатында, татарларның олыс идарәләренә һәм полициягә ышанычы кечкенә икәнен билгеләп үтеп, алар арасында чукындыру хакында сүз куерткан олыс башлыкларының һәм писарьләрнең эшчәнлегенә җитди игътибар итәргә, хәтта җаваплылыкка тартырга чакыра[3].

Икенче сәбәпкә килгәндә, анысы дөньякүләм вакыйгаларга барып тоташа. Мәгълүм ки, 1877–1878 елларда Рәсәй империясе Төркия белән сугыша. Сугыш христиан динен тотучы Балкай славяннарын ислам дине изүеннән коткару өчен, аларның бәйсезлеге өчен алып барыла дип игълан ителә. Бу хәлләр, урысларда ватандар хисләр белән бергә, Идел-Урал буенда яшәүче мөселманнарга дошманлык хисләрен дә кузгата. Үзәк гәзитләрдә “татарлар белән башкортлар Төркиягә ярдәм итү йөзеннән кораллы чыгышлар әзерләп яталар” дигән хәбәрләр күренә башлый. Урыс булмаган җирле халыкларның йөрәк тибешен тоеп торган эчке эшләр министры Мәскәүдә чыга торган газеталарда “бу темага материаллар бастырмаска” дигән әмер бирә[4].

Татар халкының тормышы, фикер сөреше белән яхшы таныш булган күренекле мәгърифәтче И.Гаспралы да урыс газеталарында үзләре хакында

басылган мәкаләләрне мөселманнарның бик кызыксынып укулары, үзләренчә аңлатырга омтылулары, ул язмаларның халыкка көчле тәэсир итүе турында яза[5]. Шунлыктан, халык арасында “тәре айны җиңде (сүз 1877–1878 елгы урыс-төрек сугышы нәтиҗәсе турында бара – З.И.), патша хәзрәтләре, солтанга ачуы чыгып, Рәсәйдәге барлык мөселманнарны чукындырырга кушкан”[6] кебек сүзләр йөрүе гаҗәп түгел. Сугыштан кайткан урыс солдатларының һәм җирле урыс крәстияннәренең татарлардан көлеп, “төрекне җиңдек, хәзер барлык мөселманнарны да чукындырачаклар” кебек сүзләр сөйләп йөрүләре[7] халыкны бик нык борчуга сала.

Монда мәсьәләнең икенче ягы да бар. Татарлар эчке сәясәттә көчәя башлаган урыслаштыруга һәм тышкы сәясәттә мөселман халыкларын яулап алу сугышларына бербөтен итеп карыйлар. Кылыч артыннан тәре килгәнен һәм шуннан урыс тәртипләре урнаштырылуны исәпкә алсаң, алар хаклы да кебек. Ислам дине дәүләт дине дәрәҗәсендә булган Төркиянең 1877–1878 елгы сугышта җиңелүе мөселман дөньясын тетрәндерә:

**Урысның бу елларда күңеле үсте,**
**Исламның күкрәгәне тәмам кысты.**
**Шундин соң үз гаһеден[8] үзе бозды;**
**Болай булса, нә кыйлырмыз, мөселманнар?!**
**Карс, Батум, Эрзерумны ала бирде,**
**Дунай үтеп, Балканны аша йөрде.**
**Төрекнең хәлсезлеген тәмам белде,**
**Болай булса, нә кыйлырмыз, мөселманнар?!**

1878 елның сентябрендә беренчеләрдән булып Спасс өязе татар крэстияннәре күтәрелә. Октябрь аенда баш күтәрүгә күрше Чистай өязенең кайбер олыслары да кушыла. Казан губернаторы гаскәр белән бару өчен Кама, Идел елгаларында боз катып ныгуын көтеп ятканда, яман хәбәрләр Казан өязеннән килә башлый. Инструкциягә ислам динен кыса һәм татар халкының милли горурлыгын мыскыллый торган мад-дә-параграфларның мөселманнарга кагылмавы хакында өстәмәләр кертү дә крәстиян хәрәкәтен тынычландырмый, киресенчә, аның “икенче сулышын” ачып җибәргәндәй итә. Халык бу өстәмәләрне патша түрәләренең алдау алымы дип кабул итә.

1878 елның ноябрь азакларында ярсыган Кармыш олысы халкы олыс идарәсе янына җыела. Меңнән артык кеше старшина белән писерне кыйнап үч ал-макчы була. Вакытында килеп өлгергән пристав, бөтен артистлык, телмәрлек осталыгын җигеп, абруен файдаланып, халыкны юмалап, дулкынланган төркемне бераз тынычландыруга ирешә, кан коелмый кала[9].

22 ноябрьдә Балтач авылында муллалар җыены була. Дин әһелләре ни эшләргә, ни кылырга дип киңәш-табыш итәләр. Ә икенче көнне олыс идарәсе урнашкан Кече Лызи авылына бөтен Балтач олысыннан җыелган халык инструкция тараткан писерне кыйнап ташлый. Моны күреп муллалар тактиканы үзгәртәләр. Балтач мулласы Габделгаффаров, мәхәлләдән 450 сум акча җыеп, авылдашы М.Хөсәенов белән инструкцияне гамәлдән чыгару максатында 26 ноябрьдә губернатор янына Казанга китә[10].

Арча, Яңа Кишет олысларындагы чуалышларны патша түрәләре тынычландыруга ирешәләр.

Казан өязендә киң җәелгән милли-азатлык хәрәкәте татар авылындагы эчке каршылыкларны ачып сала, старосталарны алыштыру башлана. Мәгълүм булганча, староста һәм сотский кебек җәмәгать белән идарә итә торган урыннарга татарлар, гадәттә, авылның нык тормышлы кешеләрен, мөлкәтлерәкләрне сайлыйлар. Хуҗалыклардан салым җыйганда һәм төрле йөкләмәләрне үтәүдә җирле хакимият белән полициянең уң кулы булган авыл җитәкчеләренә каршы көрәш “дини” юнәлештә бара. Аларны урыс түрәләренә сатылуда һәм чукындыру эшенә хезмәт итүдә гаепләп кыйныйлар, староста билгесен һәм мөһерен тартып алып, җыенда

үзләре арасыннан яңа кешеләр сайлап куя башлыйлар. Гадәттә, җирле хакимият белән алыш-биреш итү авыл старостасы аркылы тормышка ашырыла, шунлыктан халык үз арасыннан иң ышанычлыларны сайлый.

Олы Мәңгәр, Олы Әтнә, Мәмсә олысларында чуалышларны бетерү өчен ни эшләргә белмичә гаҗиз булган өяз исправнигы, инструкциядә киткән ялгышны аңлату өчен дип билгеле бер көнне олыс идарәләренә, һәр авылдан старосталар һәм “ышанычлы” крәстиян-нәрдән өчәр кеше җыярга боера. Исправник үзе дә сизмәстән халыкның чыгышына этәргеч бирә, восстание көнен билгели. Аның кушуы буенча, 26 ноябрьдә Олы Мәңгәр авылына депутатцияләр генә түгел, ә олысның 12 авылыннан да халык җыела. Җыенны тынычландырырга омтылучы исправник исеменә янау сүзләре яңгырый. Яхшатланып исправникка ярдәм итәргә теләгән Яңа Мәңгәр авылы мулласы һәм аны якларга омтылган полицейский каты кыйнала. Губернаның земство җыелышында әгъза булып торучы татар крәстияне дә халыкка каршы сөйли башлагач, аңа “урыска сатылган” дигән мөһер сугылып, шул ук язмышка дучар була. Олыс старшинасы, писер һәм исправник, ыгы-зыгыдан файдаланып, идарә бинасы эченә кереп бикләнәләр. Халык бераз тынычлангач, алар барысы да авылдан чыгып китү ягын карыйлар.

Икенче көнне дә халык җыены хакында хәбәр алган исправник кабат Олы Мәңгәргә барырга мәҗбүр була, Халык губернаның земство җыелышында әгъза булып торучыны, урыс хакимиятенә динне сатучы буларак, җәза йөзеннән Себергә сөрү турында җыен карары чыгара. Халыкны санлата алмаган исправник авылдан чыгып киткәч, татарлар аның алдында куйган таләпләрен тормышка ашыра башлыйлар: 12 авылның да старосталарын алыштырып, олыс старшинасын да, писерен да яңаны сайлап куялар. Сыйнфый көрәшнең иң югары чагылышы буларак, мәхәллә эчендәге каршылыклар шул рәвешле чагылыш таба.

25 ноябрьдә. Олы Әтнә авылына җыелган һем исправникның “сезне чукындырырга җыенмыйлар” дигән вәгъдәсе белән бераз тынычланып таралышкан олыс халкы, ике көн үтүгә, 27 ноябрьдә яңадан күтәрелә, 1877 елгы ачлык аркасында орлык һәм азык-төлек сорап исемлек төзелгән була, һәр өй хуҗасының имзасы, тамгасы куелып, урысча язылган бу гаризада, (татарча язу законсыз саналган, туган телдә нинди дә булса карар чыгару, гариза язу җирле хакимияткә каршы чыгу дип танылган һәм гаеплеләр төрмәгә ябыла торган булган) “татарлар чукынырга риза” дигән җөмлә дә бар икән кебек сүз таралгач, олыс идарәсенә бәреп кереп, әлеге кәгазьләрне юк итә, старшина белән писерне каты кыйный. Шул ук көнне кичен Олы Этнагә исправник килгәндә инде халык таралган, эш узган була. Бу вакыт олыстагы барлык авылларның старосталары алышына, яңа старшина сайлана, идарә бинасы туздырыла. Исправникны идарәдә халык калдырган дүрт каравылчы гына каршы ала.

Шулай итеп, бер үк көнне, 27 ноябрьдә Олы Мәңгәр, Олы Әтнә олысларында крәстиян үзидарәсе оеша, Беренчесендә ул 12 авылдан торган һәм, 1858 елгы X ревизия мәгълүматлары буенча, 4 меңнән артык ир-атны берләштергән, ә икенчесендә исә 12 татар авылы һәм 3,5 мең ир-ат була.

Ә күрше Мәмсә олысында хәлләр тагын да кискенрәк тора. 23 ноябрьдә авылларга таратылган мәгълүм инструкциягә өстәмәләр халыкның ачуын көчәйтә генә. 27 ноябрьдә халык, Яңа Кенәр авылына җыелып, җәй көне инструкцияне тараткан һәм 11 ел эшләү дәверендә үзләренең бәгырен корыткан писер Завалишинның Казаннан кайтып төшүен көтә. Үзенең ярсыган халык кочагына эләгәсе турында хәбәр алган Завалишин становой пристав янына барып хәлне сөйләп бирә. Баш полицейский Яңа Кенәрдә волость җыенын икенче көнне үткәрергә кушып йомышчы җибәрә, әмма үзе Олы Мәңгәр олысындагы вакыйгалар белән тоткарланып, вакытында килеп җитә алмый. Алдан сөйләшенгән буенча, приставның яклавына ышанып, 28е көнне Яңа Кенәргә Завалишин да килә. һәр авылдан чакыртылган 5–6 кеше урынына бөтен авыллары белән кубып килгән халык олыс идарәсеннән Завалишин белән старшина Галиевнең чыгуын таләп итә дә, беренчесен каты кыйнап, икенчесе урынына яңа старшина сайлап куя. Галиев

кесәсендә идарәнең акча сандыгы ачкычы гына кала. Аннан соңгы ике көндә Мәмсә, Шушмабаш, Ашытбаш, Ишнарат, Яңа Кенәр авылларында старосталар кыйнала һәм Кенәрдәге кебек алыштырыла. Олыс идарәләре әгъзалары кулга алынып, бикләп куела һәм сак астына алына. Яңа Кенәр авылына илтә торган барлык' юлларга сакчылар куела, һәм алар килүче-китүче һәр кешене тикшерә башлыйлар. Шундыйларның берсе, өяз җитәкчеләре әмере буенча Яңа Кенәргә хәлне ачыкларга тибәрелгән полицейский, сакларның берсенә эләгеп кыйнала[11]. Мәмсә олысында баш күтәрү .тагын бер ягы белән игътибарга лаек. Халык куйган таләпне үтәп, олыста яшәгән унлап урыс "промышленниклары" (төрле һенәрчеләр) 24 сәгать эчендә торган җирләрен калдырып китәләр. Шулай 1–2 көн эчендә Казан өязенең, шактый зур өлешендә (Мәмсә олысында 20 авыл, 4 мең ир-ат исәпләнә) авыл һәм олыс дәрәҗәләрендә татар халкының милли крәстиян үзидарәләре төзелә. Шулай итеп, вакыйгалар ничек тиз кабынса, шулай ук сүнеп-сү-релеп калган кебек була. Бу аңлашыла да. Татар халкы, урыс түрәләрен куып җибәреп, үз арасыннан яңа хакимият вәкилләрен сайлап куя – кыскасы, үз теләкләренә ирешә.

Казан өязендә ирек алу, урыс түрәләрен куу турындагы хәбәр яшен тизлеге белән тирә-яккә тарала. Күрше өязләрдән, Вятка губернасыннан бу олысларга халык агыла башлый. Губернатор Н.Я.Скарятин эчке эшләр министрына җибәргән рапортында "башка төбәкләрдән җыелган крәстияннәр монда эшнең ни белән бетәсен белгәннән соң үзләре дә шуны ук кабатларга: олыс һәм авыл түрәләренең барысын да кыйнап, тулы үзидарә һәм анархия урнаштырырга телиләр иде", дип яза[12].

Губернатор Спасс өязендәге баш күтәрүне бастырырга дип әзерләнгән батальон белән Казан өязенең баш күтәргән башка олысларына юнәлә. 1878 елның 4 декабре мондагы халык өчен үзидарәне җимерү, баш күтәрүне бастыру, җәзалаулар башлану көне була.

Татар крәстияннәре баш күтәргәч, курыккан Казан аяз исправнигы, чиргә сабышып, гаскәргә ияреп килә алмас хәлгә төшә. Хәер, берьюлы өч олыста татарлар-ларның күтәрелеп чыгуы, Н.Я.Скарятин әйтүенчә, бер исправникның гына түгел, ә тирә-як урыс авылларында һәм олысларында да курку-паника тудыра.

Олы Мәңгәр авылында халыкны бодай җәзалыйлар. Солдатлар халыкны, мылтыкларын әзер тотып, дүрт яктан уратып алалар. Чыпчык, Мүлмә олысларыннан татарларга җәза бирер өчен чакыртылган 500 ләп урыс крәстияне, карга тезләндерелгән кешеләр арасыннан теләсә-кайсын тартып чыгарып, аларның чишенгәннәрен дә көтмичә, киемнәрен йолкып салдырып, җиргә егып, берсе кыйналучының башына утырып, икенчесе аякларын тотып, өченчесе чыбык белән суга: бер кешегә өчәү "хезмәт күрсәтә". Бу эш өчен Олы Мәңгәрдә ике ат йөге чыбык сарыф ителә[13]. Барлыгы эч олыста ярты меңгә якын кеше суктырыла. Күп крәстияннәргә йөзәр чыбык эләгә.

Баш күтәрүчеләрне җәзалауда губернатор үзе үрнәк күрсәтеп йөри. Шул ук Олы Мәңгәр авылында сүз әйтергә дә ирек бирмичә: "Менә сезгә Мөхәммәт, менә сезгә Корьән, менә сез кабул итәргә теләмәгән инструкциянең 6 нчы параграфы",– дип җикеренеп, картларның сакалын йолкый, әле аягы белән тибеп, әле кулындагы таягы белән кизәнеп, тезләндерелгән кешеләрнең күкрәгенә, йөзенә суга. Ул Яңа Кенәр, Олы Әтна авылларындагы суктыруга да катнашып йөри.

Яңа Кенәр авылында писер Завалишинны кыйнашкан дип шик төшкән крәстияннәргә богаулар кигезәләр. Барлыгы 12 кеше кулга алына. Шуларның тугызын суд түбәндәгечә хөкем итә: өчесен Себергә каторгага (4 ел да 1 айга), дүрт кеше – Себергә яшәргә сөрелә, ике кеше – арестант роталарына билгеләнә (өч елга һәм ел ярымга). Нәтиҗәдә милли-азатлык хәрәкәте байрагы астында барган баш күтәрүне түрәләр бер писер Завалишинны кыйнауга кайтарып калдыралар. Солдатлар һәм аларга ярдәмгә китерелгән урыс крәстияннәре җәзалап кыйнау вакытында халыктан талап акча, икмәк мал-туар һәм башка азык-төлекләр җыялар. "Чыбык ашау" татар крәстияннәре өчен бик кыйммәткә – акча берәмлегенә күчереп хисаплаганда 971 сум 17 тиенгә төшә[14].

Инде чуалышларны восстание дәрәҗәсенә күтәргән тагын өч сәбәпне атап китәргә кирәк. Казан арты XIX йөзнең икенче яртысында–Тау ягының Спасе өязе кебек үк, капиталистик мөнәсәбәтләр шактый тирән үтеп кергән төбәк. Әлбәттә, буржуаз мөнәсәбәтләрнең нәтиҗәсе буларак, татар җәмгыятендә дә сыйнфый каршылыклар кискенләшә, ачлык еллары бу каршылыкларны көчәйтә, авылдагы күпчелек крәстиян хуҗалыгы бөлә. Шул ук вакытта Казан артының – җимерелгән Казан ханлыгының (ә Спасс өязенең – Болгар дәүләтенең) үзәк районнары икәнен дә онытырга ярамый. Халыкның үзаңында кайчандыр үз дәүләте булганлыгы яшәп килә, милли үзаңның көче восстаниенең куәтендә һәм зурлыгында чагылыш таба дисәк ялгыш булмас. Өченче сәбәп итеп төбәктә татар халкының бербөтен булып яшәвен әйтергә кирәк (өч олыска бары бер урыс авылы). “Күршесенең иңен тоеп” эш иткән халык үзен зур көч итеп сизә, бу хәл аларның чыгышларына кискенлек һәм тәвәккәллек өсти.

Берьюлы өч олыста халыкның властьны тулысы белән уз кулына алу очрагы–XIX йөзнең икенче яртысында бердәнбер һәм тиңе булмаган хәл. Табигый рәвештә: “Дин әһелләре һәм бу төбәктә яшәгән милли буржуазия вәкилләре дә баш күтәрүдә катнашканмы?” – дигән сорау туа.

Түрәләргә ярдәм итәргә омтылганы өчен Яңа Мәңгәр мулласының кыйналуы турында язган идек. Губернатор Н.Я.Скарятин да, гаскәр белән килгәч, Казан өязе муллаларының башлап йөрүчеләрне күрсәтүләрен, чуалыш барышында руханиларның хөкүмәт яклы булуларын билгеләп үтә. Бары Олы Мәңгәр олысы Күшәр авылы мулласы Сабирҗан Якупов кына баш күтәрүдә катнашканы өчен кулга алына.

Ләкин бит һәр фетнәнең әзерлек чоры бар. Халык күңелендәге ачуны дөрләтеп, аны милләт өчен көрәшкә әзерләүдә халыкны инструкциядә язылган ислам динен кысу турында маддә-параграфларга каршы туплауда дин әһәлләренең роле зур була. Мисал өчен октябрь-ноябрь айларында мөфтигә һәм югары хакимият вәкилләренә шикаять-кисәтүләр язу кампаниясен атарга була. Бу эшләр муллалар һәм авылның бай катламы катнашы белен эшләнә. 1877 елгы ачлыктан соң авыр хәлдә калган татар крәстияннәренең үтенечләр бирү өчен, әлбәттә, акчалары булмый, бу эшне тәэмин итү тулысы белән муллалар һәм авыл байлары җилкәсенә төшә. Губернатор Н.Я.Скарятин да, мондый көчле милли-азатлык чыгышында татар буржуазиясе вәкилләренең катнашы бар, дип белдерә. Ул фетнә барышында Мәңгәрдә яшәүче сәүдәгәрләр Бәкерев белән Адәмевнең авылда булуларын, халык арасында зур абруйга ия бу кешеләр: “баш күтәрүне туктатасылары килгән булса, башкарып чыга алган булырлар иде”,– дип билгеләп үтә. Бәкерев белән Адәмев олыска гаскәр килер алдыннан гына Казанга китеп баралар һәм губернатор килгән көнне әйләнеп кайталар. Скарятингә үзләренең тугрылыкларын күрсәткән булып, халыкны суктыруны хуплыйлар[15] .

Дин әһелләренең, милли буржуазиянең йогынтысын, аларның баш күтәрүгә катнашканмы-юкмы икәнлеге турындагы соңгы сүзне татар кулъязмалары табылган очракта гына әйтергә мөмкин булачак. Чөнки урыс түрәләренең күп тапкырлар раславынча, татар крәсти-яннәре бик сирәк очракта гына дин әһелләрен саталар. Әгәр дә берәрсе руханиларның хөкүмәткә каршы эшчәнлеге турында ни дә булса ычкындырса, барыбер суд юлы белән мулланы җаваплылыкка тартып булмый, чөнки башкалар киресен сөйли торган була. Авыл мәнфәгатьләрен (динне яклау юлында йөрүчеләр хакында әйткән дә юк инде) исәпкә алмыйча түрәләргә хәбәр бирүче кеше бөтен халык дошманына әверелә.

Баш күтәрүгә дин әһелләренең һәм милли буржуазия вәкилләренең йогынтысын раслап тагын бер дәлил китерергә мөмкин. Баш күтәрүне бастырган вакытта халык Н.Я.Скарятиннан мөфтине Диния нәзарәтенә караган мөселманнар тарафыннан сайлап кую тәртибен кертүне сорый. (Демократик юл – гомуми сайлаулар үткәрү юлы белән дин башлыгын билгеләү мәсьәләсе кабыргасы белән беренче Рәсәй революциясе елларында гына куела.) Шунысы кызык, 1879 елның январенда Казан байлары Юнысов, Апанаев, Әҗемев, Галиев губернатор янына

кереп, чирләп киткән мөфти Тәфкилев белән ул-бу була калса, аның урынына яңа кандидат сайлау турында сөйләшү сылтавы белән, эчке эшләр министры янына Петербургка депутация җибәрергә рөхсәт сорыйлар. Аның составына Юнысов, Апаков, Үтәмешев, Апанаевлар керергә тиеш була. XIX йөзнең 80–90 нчы елларында татар буржуазиясенең милли-азатлык хәрәкәте белән ничек җитәкчелек итүен өйрәнү нәтиҗәсендә без бу адымның Казан өязендәге восстаниедән һәм бөтен губернага җәелгән татар крәстияннәре хәрәкәтеннән файдаланып, аның ышыгында патша хөкүмәтеннән аз гына булса да милли изүне йомшарту, аңардан ташламалар ясату өчен эшләнгәнен әйтә алабыз.

Губернатор соравы буенча, татар байлары аны Эчке эшләр министры өстәленә салыначак мәсьәләләр бәйләме белән таныштыралар. Сәүдәгәрләр татар мәктәпләрен халык мәгарифе министрлыгы карамагыннан алу (бу таләп хәзерге көннәрдә татар мәктәпләрен урыс мәгарифе системасыннан аеру турындагы таләпләргә аваздаш. Йөз ел узган – ә мәсьәлә шул дәрәҗәгә төшкән икән!– Ред.) һәм муллаларны урыс телен белү мәҗбүрилегеннән азат итү, христиан дине әһелләре һәм псаломщиклары файдаланган хәрби хезмәткә алынмау турындагы льготаны мәдрәсә шәкертләре өчен дә куллануны күтәрәләр.

Алар кузгатырга уйлаган икенче бәйләм сораулар турыдан-туры ислам дине белән бәйле була. Казан өязендәге суктырулар вакытында татар халкының җан авазы булып яңгыраган “мөфтине барлык мөселманнар сайларга тиеш” дигән таләпләрнең демократия “тузанын” бераз кагып, ә бәлки Рәсәй чынбарлыгына сыешмый торган, моңарчы тиңе булмаган “дорфалык” икәнен яхшы аңлап, байлар мөфтине Диния нәзарәтенә ки раган руханилар (Диния нәзарәтенә 17 губерна керә) сайлап куйсын дип үзгәртәләр. Закон буенча мөфтине тәкъдим ителгән өч кандидаттан эчке эшләр министры сайлап куярга тиеш була. Шушы таләпнең дәвамы ител сәүдәгәрләр тәкъдим иткәнчә, Диния Нәзарәтендә сайлана торган казыйларны Казан губернасы руханилары белән генә түгел, ә Рәсәйнең Аурупа өлеше губерналарындагы барлык руханиларын да катнаштырып билгеләүне атарга мөмкин. Байлар казыйларга түләү хакы күтәрү турында да әйтәләр. Юнысовлар куйган соңгы таләп бүген дә үзенең зарурилыгын югалтмаган. Ул – ислам динен тотучыларга ял көне итеп җомга кенш рәсмиләштерү һәм дәүләт оешмаларында эшләүчеләр өчен дә ислам дине бәйрәмнәре көннәрендә ял бирү мәсьәләсе[16] .

Губерна идарәсендә милли буржуазия вәкилләренең позициясен һәм карашларын ачыкларга ярдәм итә торган тагын бер вакыйга булып ала. Н.Я.Скарятин бу мәсьләләр белән югарыга мөрәҗәгать итәргә мех-кин түгел дип белдергәч, Казан байлары кабат беренче төркем мәсьәләләрне карауны сорыйлар. Күргәнебезчә, алар урыслаштыруга каршы булган һәм татар милләте үсешенә зыян салучы социаль мәсьәләләрне беренче нәүбәткә куйган.

Татар крәстияннәре хәрәкәте милли буржуазия аз кипләренә кыюлык өсти, алармы гомер буена кар тамга салынып калудан курыкмыйча, урыс милләт белән хокукларны тигезләү өчен шактый кыю адьи ясауга этәрә. Ул заманда мондый тәкъдимнәр белән чыгуның гади адым гына булмавын раслау өчен Казан губернаторыннан хәбәр алган Эчке эшләр министрының, Н.Я.Скарятинны йомшаклыкта гаепләп, аны күтәрелгән мәсьәләләр буенча бөтенләй сөйләшеп тор мыйча, алармы шунда үк кире какмавын билгеләп үзенең канәгатьсезлеген белдерүен әйтеп китү дә җитә.

Шулай итеп, крәстияннәр авызыннан чыккан таләпләрнең ике ай үтмәс борын ук татар байларының кабатлавын, соңгыларының эшне сак һәм, гадәттәгечә итәк астыннан йөртүен исәпкә алсак, ике арада сузылган җепләрнең берсен һәрхәлдә күрергә була.

Губернада җәелгән милли-азатлык хәрәкәтенә өч олыста кузгалган фетнәләрнең тәэсире нинәди? Гомүмән алганда– тискәре. Патша түрәләренең гаскәр чакырту белән янауларының буш сүз генә түгел икәне белгән, базарларга килгәч баш күтәрүчеләрнең каты җәзага тартылуын ишеткән халыкка андый сuктыр айныткыч тәэсир ясый. Кайбер авылларның үзләре теләп патша хакимиятенә

буйсыну очраклары билгеле Шул ук вакытта Спасс өязендә баш күтәреп, крәстиян үзидарәләре оештырган татарларга бу хәл бер елдан артык (!) җирле хакимиятне санламыйча, аларны басу капкасыннан үткәрмичә яшәргә мөмкинлек бирә. Аларны 1879 елның декабренә кадәр гаскәр җибәрелүдән саклап тота.

1879 елның язында милли буржуазия вәкилләре рәнҗетелгән һәм кимсетелгән Казан өязе халкы исеменнән губернатор Н.Я.Скарятин өстеннән судсыз-нисез суктырган өчен югарыдагы хакимнәргә шикаять бирү кампаниясен оештыралар. Н.Я.Скарятин бу эт татар байлары кулы уйнаганын ачыктан-ачык әйтә. 1925 елда күренекле татар тарихчысы Газиз Гобәйдуллин шундый бер шикаятькә язган искәрмәсендә, документның Юнысовлар архивыннан булуын билгеләп үтә һәм бу губернаторның сүзләрен раслый. Сенатта аңа карата болытлар куеруын белгән һәм җиде кат үлчәп эш итәргә тырышкан Н.Я.Скарятин, эчке эшләр министрлыгына язган хатында баш күтәрүне көч кулланмыйча гына бастырырга мөмкин булган бөтен алымнарның файдаланып бетүен күрсәткәч кенә һәм югарыдан фатиха алгач кына бер батальон солдат белән Спасс өязенә юнәлә. Ләкин мондый саклык чаралары да аны губернатор кәнәфиендә саклап кала алмый. Ахыр чиктә ул эшеннән азат ителә һәм югары пенсия белән (нәкъ хәзерге түрәләр сыман.– Ред.) отставкага озатыла.

Казан губернасындагы крәстияннәр хәрәкәте тәэсирендә Самара, Сембер, Вятка һ.б. Идел буе губерналарында да чыгышлар күзәтелә. И.Гаспралы “Төньяк мөселманнарның көчләп чукындырылуы турында, мәчетләрне чиркәү манаралары белән алыштыру турында сүзләр... Касыймнан алып Ташкентка, Пермьнан алып Ленкоранга кадәр мөселманнар яшәгән өлкәләрне аякка бастырдылар, барлык мөселманнарның хөкүмәткә ышанычларын бетерә яздылар, дип күрсәтте[17] .

1878 елгы Казан өязе татар крәстияннәре восстаниесендә ул чордагы җәмгыять тормышының күп кимчелекләре һәм караңгы яклары чагылыш таба. Бу вакыйгага әлегә тиешле бәя бирелмәгән. Язылганнарга нәтиҗә ясап түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. XIX йөзнең икенче яртысындагы крәстияннәр хәрәкәтендә тиңе булмаган, олыс дәрәҗәләрендә милли крәстиян үзидарәләре оешу белән тәмамланган һәм аяусыз бастырылган баш күтәрү бөтен Идел буе крәстиян хәрәкәтенә зур йогынты ясый. Татар халкының баш күтәрүе патша хөкүмәтенең урыслаштыру сәясәтен акрынайта, милли изү буенча башкарылачак һәр эшне, һәр адымны киләчәктә төптән уйлап үткәрүне таләп итә башлый. Вакыйгалар татар крәстияннәренең милли аңы шактый югары икәнен, үз эчләренә урыслаштыру элементын үткәрмәс өчен, ислам динен аяк астына салып таптамас өчен көрәшкә күтәрелүләрен күрсәтә.

Татар крәстияннәре тагын өч җиңүгә ирешәләр. Беренчесе – Ислам динен кысуга юнәлдерелгән инструкция параграфлары барысы да диярлек юкка чыгарыла. Икенчесе – халыкны хөкемсез җәзалауны оештырган өчен Казан губернаторы Н.Я.Скарятин эшеннән алына. Гади халык таләбе буенча, алай гына да түгел, кара халыкның да “инородец” кушаматлы “татар” дигәненең таләбе буенча берәр түрәнең “җавапка тартылуын”, губернатор кадәр губернаторның отставкага озагылуы XIX йөзнең икенче яртысында безгә билгеле бердәнбер очрак. Өченчесе – һәм иң мөһиме – Казан губернасындагы татарлар яшәгән ун өязнең тугызын чолгап алган татар крәстияннәре хәрәкәте бердәм чыгыш ясаганда җиңүгә ирешеп була дигән ышаныч тудыра.

Мондый фактларны анализлау, моңарчы урыс алпавытлары, гомумән хаким сыйныф белән бер лагерьга “куып кертелгән” һәм шулай “кул селтәнгән” татар милли буржуазиясе, мөселман дин әһелләренең милли мәсьәләгә булган мөнәсәбәтләрен бик уйлап һәм төрле яктан тикшергәннән соң гына нәтиҗә чыгарырга мөмкин икәнен искәртә.

[1] ТССР ҮДА, 1 фонд, 3 тасвирлама, 4345 эш, 34 бит.

[2] Материалы по истории Татарии второй половины XIX ве-ка. Ч. 1. М.–Л., 1936, 360, 408 бб.

[3] ТССР ҮДА, 1 фонд, 3 тасвирлама, 4627 эш, 304–305 бб.

[4] Материалы по истории Татарии.. 347–348 бб.
[5] Тәрҗеман, 1892 ел, №43.
[6] ТССР ҮДА, 1 ФОНД, 3 тасвирлама, 4345 эш, 63 б.
[7] Материалы по истории Татарии... с. 348.
[8] Гаһед– килешү.
[9] ТССР ҮДА, 1 фонд, 3 тасвирлама, 4627 эш, 68 б.
[10] Шунда ук, 4345 эш, 53–54, 56 бб.
[11] Смыков Ю. И. Крестьяне Среднего Поволжья в борьбе за эемлю и волю. Казан, 1973, 169–173 бб.
[12] СССРның ҮДТА, 1282 фонд, 2 тасв., 1083 эш, 24 б.
[13] Али Рәхим. К вопросу о татарском крестьянском движении 1878 г .– Вестник научного Общества Татароведения. №8, 1928, 147 б.
[14] СССРның ҮДТА, 1356 ар., 1 тасв., 46 эш, 1 б.
[15] ТССР ҮДА, 1282 ф., 1 тасв, 46 эш, 1 б.
[16] Материалы по истории Татарии... 421–422 бб.
[17] Исмагил бей Гаспринский. Русское мусульманство. Оксфорд, 1985, 49 б.